РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

«22» апрель, 2019 ел Олы Кайбыч авылы № 161

Кайбыч муниципаль районы Советының 2017 елның 15 декабрендәге «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы милке булган, өченче затлар хокукларыннан азат булган (кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының милек хокукларыннан тыш), кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын хасил итүче оешмаларга хуҗа булу һәм (яки) куллануга тапшыру өчен алдан билгеләнгән муниципаль милек (җир биләмәләреннән тыш) исемлеген формалаштыру, алып бару һәм бастыру Тәртибен раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

2018 елның 3нче мартындагы 185-ФЗ номерлы «Кече һәм урта эшмәкәрлек субъекларына мөлкәти яктан ярдәм күрсәтүне киңәйтү максатыннан, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законы нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының 2017 елның 15 декабрендәге 105нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы милке булган, өченче затлар хокукларыннан азат булган (кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының милек хокукларыннан тыш), кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын хасил итүче оешмаларга хуҗа булу һәм (яки) куллануга тапшыру өчен алдан билгеләнгән муниципаль милек (җир биләмәләреннән тыш) исемлеген формалаштыру, алып бару һәм бастыру тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 1 бүлекнең 1.3. пунктын түбәндәгечә бәян итәргә: «1.3.«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» Федераль законының 18 статьясының 4 өлешендә күрсәтелгән исемлекләргә кертелгән дәүләт һәм муниципаль милекне мондый милекне 2008 елның 22 июлендәге 159-ФЗ «Дәүләт милкендә һәм муниципаль милектә булган һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан арендаланган күчемсез милекне

читләштерү үзенчәлекләре, һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль Законында күрсәтелгәннәргә нигезләнеп һәм Россия Федерациясе Җир Кодексының 39.3 статьясының 2 пункты 6,8,9 пунктасларында күрсәтелгән очраклардан тыш, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын читләштереп милек хокукларыннан тыш сату тыела. Күрсәтелгән милеккә карата шулай ук аның белән куллану хокукын үз бәясенә бирү, аның белән куллану хокукын залогка бирү һәм аның белән куллану хокукларын хуҗалык эшчәнлегенең теләсә кайсы башка субъектларына башлангыч капитал итеп куллану, мондый милек арендасы килешүләре буенча хокук һәм бурычларны өченче затларга тапшыру, субарендага бирү, мондый милекне кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына субарендага кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын хасил итүче оешмалар бирүдән, һәм субарендага 2006 елның 26 июлендәге 135-ФЗ номерлы «Конкуренцияне саклау турында» Федераль законының 17.1 статьясының 1 өлеше 14 пунктында күрсәтелгән милек бирелгән очрактан тыш тыела.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының информацион-телекоммуникацион сайтында һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң (халыкка таратылганнан соң ) көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы җир һәм милек мөнәсәбәтләре палатасы» МКУ рәисе О.Д. Макаровага йөкләргә.

Совет Рәисе, Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы Башлыгы А. И. Рәхмәтуллин